СОЛДАТЛАРГА ЯРДӘМГӘ

Татарстаннан махсус хәрби операциягә броньланган машина җибәрделәр

> 2

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлекләре

> 3

МӘЧЕ ҮПКӘСЕ

Безнең гамәлләребезгә эте дә, мәчесе дә бәя бирергә тырыша икән

> 4

ТӘРТӘ АРАСЫНА КЕРҮ

Озын яллардан соң гадәти тормышка ничек кайтырга?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 2 (29162) | Чәршәмбе | 10 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

КЕМГӘ – ЯЛ, КЕМГӘ – ЭШ

Бәйрәм нәтиҗәләре

Яңа ел каникулы, озын яллар тәмам. Хәзер җиң сызганып, эшкә керешер вакыт, тик аңа кадәр нәтиҗәләрне барлап чыгарга булдык. Гыйнварның беренче атнасы кемнәрнедер сөендерсә, икенче берәүләрне көендерергә дә өлгерде.

Илдар Мөхәммәтҗанов / Архив фотосы

Яңа елның беренче көнендә республика халкы 60 кешегә ишәйде.

Йортларда

Яңа ел безгә чын, ак карлы һәм суык көннәре белән килде. Татарстанда, Россиянең башка күп кенә төбәкләрендәге шикелле, инде атнадан артык салкын һава торышы саклана.

Кызганыч, еш кына мондый һава торышы янгыннарның кинәт артуына да сәбәпче була.

– Статистика мәгълүматлары күрсәткәнчә, бәйрәм көннәрендә янгыннар арта. Моңа салкын һава торышы да сәбәпче, чөнки кешеләр, бинаны җылытырга теләп, саклык чараларын боза, – ди Татарстанның Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының матбугат белән эшләү буенча бүлек башлыгы Андрей Родыгин.

Шулай итеп, республиканың янгын күзәтчелеге буенча баш дәүләт инспекторы Максим Трущин журналистлар белән очрашу вакытында 30 декабрьдән 9 гыйнварга кадәр Татарстанда 87 янгын чыгуын һәм аларда 5 кешенең һәлак булуын әйтте. Узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, янгыннар – 32,6 процентка, зыян күрүчеләр – 41,7 процентка, ә гомере өзелгәннәр бер кешегә кимрәк. Аның сүзләренчә, янгыннар күпчелек очракта мичләрне дөрес кулланмау һәм дөрес урнаштырмау аркасында килеп чыга. Шулай ук аларга ут белән саксыз эш итү, электр җиһазларын куллану кагыйдәләрен бозу да сәбәпче. Күпчелек очракта янгын сүндерүчеләргә торак йортлардагы янгыннарны сүндерергә туры килә.

Әйтик, 8 гыйнварда Чирмешәндә шәхси йортта килеп чыккан янгынның нәтиҗәсе бигрәк тә аянычлы. Кичке алтылар тирәсендә килеп чыккан көчле ут 6 яшьлек кызчыкның гомерен өзә. Ут эченнән 36 яшьлек әнисен алып чыгалар. Хәзерге вакытта аның да хәле авыр, яшь әнинең гомере өчен табиблар көрәшә. Әлегә ут чыгуның сәбәпләре билгесез, ди белгечләр.

Моннан тыш, 9 гыйнварга каршы төндә Казанның Максимов урамындагы күпфатирлы йортта газ шартлаган. Бу хәл газ җиһазыннан дөрес файдаланмау аркасында килеп чыккан булырга тиеш, дип фаразлыйлар.

Юлларда

Кызганыч, бәйрәм кәефен юлларда булган аварияләр да ямьсезләде. Татарстанның ЮХИДИ идарәсе китергән мәгълүматлар буенча, 1 гыйнвардан 8 гыйнварга кадәр юлларда 39 юл-транспорт һәлакәте күзәтелгән, аларда биш кешенең гомере өзелгән, 60ы төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган. Әйтик, 7 гыйнвар көнне иртән Татарстанның Баулы районында юл-транспорт һәлакәте булган. 48 яшьлек хатын-кыз авария урынында ук вафат булган, тагын биш кеше зыян күргән.

Хастаханәләрдә

Бәйрәм көннәрендә табиблар да уяулыкны югалтмады. Әйтик, беренче атнада Казанның Ашыгыч ярдәм хезмәте 24 меңнән артык мөрәҗәгать кабул иткән. Аларның күпчелеге ОРВИ белән бәйле булган. Моннан тыш, балалар саулыгына һәм җәмәгать урыннарында җәрәхәт алуга бәйле шалтыратулар да күп булган. Аның каравы юллардагы бозлавык аркасында егылып имгәнүчеләр саны кимегән. Мәсәлән, гыйнварның беренче атнасында 57 тапкыр мөрәҗәгать итсәләр, узган ел ахырында мондый шалтыратуларның саны 147 булган.

Гаиләләрдә

Билгеле, озын яллар күңелсез вакыйгалары белән генә истә калмады. Якыннар, туганнар белән очрашу, аралашудан алган матур кичерешләр белән бергә сөенечле вакыйгалары да җитәрлек булды. Әйтик, озын ялларда кайсыдыр гаиләләр сабый туу шатлыгын кичерде. Аждаһа елының беренче көнендә республика халкы 60 кешегә ишәйде. Яңа елны котлап аваз салган сабыйларның 32се малай булса, 28е – кызлар. Беренче бала Чаллыда туган. Аңа Идел дип исем биргәннәр. Бер атна эчендә Казанда 117 сабый дөньяга килгән.

Җәмәгать урыннарында

Яңа ел табынына әзерләгән сый-нигъмәтләр белән сыйланып, йокыларын туйдыргач, халык кабаттан кибет, сәүдә үзәкләре, базарларга юл алды. Бу юлы инде кием-салым артыннан. Алар акча янчыкларын бушатса, сатучылар мөмкин булганча табыш кертеп калырга тырышты.

– Без инде 2 гыйнвардан бирле эштә, – диде «ВТ» хәбәрчесенә кием-салым һәм аксессуарлар кибетендә эшләүче менеджер Айгөл Ибраһимова. – Ел ахырында һәм бу ял көннәрендә кибеттән кеше өзелмәде. Яңа елга кадәр бүләкләр алсалар, быел башлыча кием-салым сайладылар. Озын ялларда сату 60 процентка артты. Шуңа күрә без бик канәгать.

Бәйрәм көннәрендә акча эшләп калырга тырышучылар арасында кинотеатрлар да бар. «Интерфакс» басмасы хәбәр итүенчә, Яңа ел каникулы вакытында Россия кинотеатрларына 14,8 млн кеше барган һәм 5,8 млрд сумга билет сатып алган. Узган ел белән чагыштырганда, бу 1,3 млрд сумга күбрәк, дип хәбәр иткән Россия мәдәният министры Ольга Любимова.

Көне билгеле

Быелгы бердәм дәүләт имтиханнары расписаниесен раслаганнар. Россия Юстиция министрлыгы бу җәһәттән документларны теркәгән дә инде.

Шулай итеп, чыгарылыш сыйныф укучылары 22 марттан 22 апрельгә кадәр имтиханны вакытыннан алда бирә алачак. Төп чоры – 23 майдан 1 июльгә кадәр, ә өстәмә чоры – 4 сентябрьдән 23 сентябрьгә кадәр. 23 майда география, рус әдәбияты һәм химия буенча имтиханнар үткәрелә. Рус теленнән БДИ – 28 майда, математикадан – 31 майда. Җәмгыять белеменнән дәүләт имтиханын – 4 июньдә, тарих һәм физика фәннәреннән – 10 июньдә, биология һәм чит телләрдән (язмача өлешен) 13 июньдә бирәчәкләр. Информатика буенча БДИ – 7 һәм 8 июньгә, чит телләрнең телдән өлеше 17–18 июньгә тәгаенләнгән. Ә инде имтиханны нигезле сәбәпләр белән вакытында тапшыра алмаганнар өчен 20 июньнән 1 июльгә кадәр барлык фәннәр буенча резерв көннәр билгеләнгән.

Тугызынчы сыйныфлар өчен төп дәүләт имтиханы (ОГЭ) 21 май – 2 июль чорында уздырылачак. Вакытыннан алда имтиханны тапшырырга теләүчеләр өчен 23 апрельдән 18 майга кадәрге чор күздә тотылган. Өстәмә көннәр 3–24 сентябрьгә билгеләнгән.

Бер елда – 19

Узган елда Татарстанда 19 мәчет ачканнар. Алар Чүпрәле, Актаныш, Әлмәт, Питрәч, Әтнә, Яңа Чишмә, Арча, Ютазы, Алабуга, Балык Бистәсе, Азнакай, Мөслим, Балтач районнарында һәм Казанның 4 районында пәйда булган.

Диния нәзарәте хәбәренә караганда, яңа төзелгән Аллаһ йортларында, намаз уку өчен мәйданчыктан тыш, уку бүлмәләре, мәҗлесләр үткәрү өчен заллар, ашханә, никахлашу үзәкләре, кибетләр, корбан чалуны оештыру һәм җеназа үткәрү урыннары, имам йорты да булдырылган.

Бүгенгә республикада барлыгы 1582 мәчет эшләп килә. Узган ел азагында Казанда Росгвардия батальоны хәрби шәһәрчегендә дә кечкенә генә Аллаһ йорты ачканнар. Аның биеклеге – 2,5 метр, ә гомуми мәйданы – 15 квадрат метр.

Өчьяклы һөҗүм

Россиядә бер үк вакытта өч төрле чир – грипп, коронавирус һәм ОРВИ тарала. Белгечләр әйтүенчә, тридемиянең башлануы турында сөйли бу. Ул февраль – март айларында гына сүрелә башлаячак.

«Известия» хәбәренә караганда, хәзерге вакытта грипп ияртүчеләр саны көннән-көн арта. Чирләүчеләр саны 10 мең кешегә 128,1 очрак (нормадан 83 процентка зуррак) туры килә.

Шул ук вакытта яңа елның беренче атнасында илдә коронавирус йоктыруның 25922 очрагы (алдагы атнадагыга караганда 56,8 процентка азрак) теркәлгән. Татарстанда да ковид белән авыручылар саны кимегән: 1–7 гыйнвар көннәрендә 1149 кешедә (алдагы атнадагы белән чагыштырганда 22,5 процентка кимрәк) чир ачыкланган.

Суыклар сыный

Республикада атна ахырына кадәр суык булачак. Ә ял көннәренә таба кар-буран да өстәләчәк.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, пәнҗешәмбе – 11 гыйнварда көндез термометрның терекөмеш баганасы –14...–19 градус, көнчыгыш төбәкләрдә –22 градус күрсәтәчәк. Төнлә –24...–29, урыны белән –34 градус. Республиканың көнбатыш төбәкләрендә буран булачак.

Җомга – 12 гыйнварда көндез һава температурасы –10...–15, төнге сәгатьләрдә –16...–21 градус чикләрендә тирбәләчәк. Буран, секундына 15–20 метр тизлектә көчле җил, юлларда – кар көртләре. Шимбә – 13 гыйнварда температура көндез –18...–23, төнлә – урыны белән –30 градуска кадәр төшәчәк.

Синоптиклар, һава салкынаю сәбәпле, 10–15 гыйнварда кисәтү игълан иткән. Бу чорда тәүлеклек уртача температура –18...–24 градус тәшкил итәчәк. Нормадан 9–15 градуска түбәнрәк күрсәткеч бу.

Коткаручылар суыкта саклык чараларын күрергә: бик кирәк булмаганда, шәхси машинага утырып, табигатькә, урманга, балык тотарга бармаска, йорт-подъездларның җылылыгын кайгыртырга, балаларның ялгызы гына урамда йөрүләренә, мичләрнең артык кызуына юл куймаска, кулдан эшләнгән мичләрдән файдаланмаска киңәш итә.

Борчыган мәсьәлә

Уйлап җыйдырасы

Теләсә кайда җыйдырырга ярамый! Россия Эчке эшләр министрлыгы белгечләре, мошенниклар корбаны булмас өчен, тагын бер киңәшне истә калдырырга өнди. Эре сәүдә үзәкләрендә, җәмәгать урыннарында телефонга зарядка җыйдыру куркыныч, дип кисәтә алар.

Билгеле булганча, бүген кеше күпләп йөри торган җирләрдә телефон, планшет ише гаджетларга зарядка җыйдыра торган махсус урыннар пәйда булды. Бер яктан бу бик уңайлы. Телефон сүнеп, элемтәсез калсаң да куркасы юк. Гаджетыңны шушы махсус өстәлдәге чыбыкка тоташтырасың да вәссәлам! Әмма белгечләр әйтүенчә, шушы чыбык аша телефонга зарарлы программа, вируслар да эләгә ала. Шул рәвешле мошенниклар кешенең телефонындагы шәхси мәгълүматларына ия булырга, хәтта онлайн банк аша картадагы акчаларын да алырга мөмкин, дип кисәтә хокук сакчылары. Яңа ел ялларында Волгоградта ике кеше шул рәвешле мошенник корбаны булырга өлгергән инде.

Мондый аяныч хәлдә калмас өчен, берничә кагыйдәне истә тотарга кирәк:

– Телефоныгызны үзегезнең USB-чыбык ярдәмендә генә «тукландырырга» тырышыгыз. Юлда чакта телефонга зарядка җыйдыру өчен кулланыла торган портатив җайланманың (повербанк. – **Ред.**) да билгеле фирманыкын гына кулланыгыз.

– USB-чыбыкны төрле максатта кулланырга мөмкин. Телефонны зарядкага кую өчен исә аның нәкъ менә шушы максатка билгеләнгәнен генә файдаланырга кирәк. Алар аша телефонга һәм телефоннан берниндн мәгълүмат та йөкләтеп булмый.

– Юлда табылган, чит кешедән алынган чыбык ярдәмендә телефонны «тукландыру» да хәтәр.

– Әгәр USB-чыбыкка тоташуга, телефонга ниндидер программа йөкләтергә рөхсәт сораган смс-хәбәр килсә, аны шундук өзегез.

Сүз уңаеннан, күптән түгел Саклык банкы ясалма интеллект ярдәмендә мошенниклар эзенә төшүнең яңа ысулын тапкан. Шул рәвешле банк хезмәткәрләре исеменнән шалтыратып, халыкны төп башына утырткан шактый кырыгалдарның эзенә төшкән алар. Ялган колл-үзәкләрнең берсе Казанда урнашкан булган. Җинаятьчел төркемдә 17 кеше исәпләнгән.

Сүзгә-сүз

Иван ЯЩЕНКО, Өзлексез математика белеме бирү үзәге директоры, математика буенча БДИ биремнәрен эшләүче комиссия җитәкчесе:

Дәрес алып барганда һәм өй эшен биргәндә укытучы бала тормышындагы иң кадерле мизгелләрне – бәхетле балачак минутларын сарыф итә. Ул бу хакыйкатьне беркайчан да исеннән чыгармаска тиеш.

(«Российская газета»дан)

ТАТАРСТАНДА – ТРАНСПЛАНТОЛОГИЯ

485 кешенең гомерен саклап калганнар

Бөер күчереп утырту – 279 операция (2023 елда – 115)

Бавыр күчереп утырту – 166 операция (2023 елда – 72)

Йөрәк күчереп утырту – 40 операция (2023 елда – 26)

*Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына таянып

СОЛДАТЛАРГА ЯРДӘМГӘ

Татарстаннан махсус хәрби операциягә броньланган машина җибәрделәр

> 2

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлекләре

> 3

МӘЧЕ УПКӘСЕ

Безнең гамәлләребезгә эте дә, мәчесе дә бәя бирергә тырыша икән

> 4

ТӘРТӘ АРАСЫНА КЕРҮ

Озын яллардан соң гадәти тормышка ничек кайтырга?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 2 (29162) | Чәршәмбе | 10 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

КЕМГӘ – ЯЛ, КЕМГӘ – ЭШ

Бәйрәм нәтиҗәләре

Яңа ел каникулы, озын яллар тәмам. Хәзер җиң сызганып, эшкә керешер вакыт, тик аңа кадәр нәтиҗәләрне барлап чыгарга булдык. Гыйнварның беренче атнасы кемнәрнедер сөендерсә, икенче берәүләрне көендерергә дә өлгерде.

Илдар Мөхәммәтҗанов / Архив фотосы

Яңа елның беренче көнендә республика халкы 60 кешегә ишәйде.

Йортларда

Яңа ел безгә чын, ак карлы һәм суык көннәре белән килде. Татарстанда, Россиянең башка күп кенә төбәкләрендәге шикелле, инде атнадан артык салкын һава торышы саклана.

Кызганыч, еш кына мондый һава торышы янгыннарның кинәт артуына да сәбәпче була.

– Статистика мәгълүматлары күрсәткәнчә, бәйрәм көннәрендә янгыннар арта. Моңа салкын һава торышы да сәбәпче, чөнки кешеләр, бинаны җылытырга теләп, саклык чараларын боза, – ди Татарстанның Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының матбугат белән эшләү буенча бүлек башлыгы Андрей Родыгин.

Шулай итеп, республиканың янгын күзәтчелеге буенча баш дәүләт инспекторы Максим Трущин журналистлар белән очрашу вакытында 30 декабрьдән 9 гыйнварга кадәр Татарстанда 87 янгын чыгуын һәм аларда 5 кешенең һәлак булуын әйтте. Узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, янгыннар – 32,6 процентка, зыян күрүчеләр – 41,7 процентка, ә гомере өзелгәннәр бер кешегә кимрәк. Аның сүзләренчә, янгыннар күпчелек очракта мичләрне дөрес кулланмау һәм дөрес урнаштырмау аркасында килеп чыга. Шулай ук аларга ут белән саксыз эш итү, электр җиһазларын куллану кагыйдәләрен бозу да сәбәпче. Күпчелек очракта янгын сүндерүчеләргә торак йортлардагы янгыннарны сүндерергә туры килә.

Әйтик, 8 гыйнварда Чирмешәндә шәхси йортта килеп чыккан янгынның нәтиҗәсе бигрәк тә аянычлы. Кичке алтылар тирәсендә килеп чыккан көчле ут 6 яшьлек кызчыкның гомерен өзә. Ут эченнән 36 яшьлек әнисен алып чыгалар. Хәзерге вакытта аның да хәле авыр, яшь әнинең гомере өчен табиблар көрәшә. Әлегә ут чыгуның сәбәпләре билгесез, ди белгечләр.

Моннан тыш, 9 гыйнварга каршы төндә Казанның Максимов урамындагы күпфатирлы йортта газ шартлаган. Бу хәл газ җиһазыннан дөрес файдаланмау аркасында килеп чыккан булырга тиеш, дип фаразлыйлар.

Юлларда

Кызганыч, бәйрәм кәефен юлларда булган аварияләр да ямьсезләде. Татарстанның ЮХИДИ идарәсе китергән мәгълүматлар буенча, 1 гыйнвардан 8 гыйнварга кадәр юлларда 39 юл-транспорт һәлакәте күзәтелгән, аларда биш кешенең гомере өзелгән, 60ы төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган. Әйтик, 7 гыйнвар көнне иртән Татарстанның Баулы районында юл-транспорт һәлакәте булган. 48 яшьлек хатын-кыз авария урынында ук вафат булган, тагын биш кеше зыян күргән.

Хастаханәләрдә

Бәйрәм көннәрендә табиблар да уяулыкны югалтмады. Әйтик, беренче атнада Казанның Ашыгыч ярдәм хезмәте 24 меңнән артык мөрәҗәгать кабул иткән. Аларның күпчелеге ОРВИ белән бәйле булган. Моннан тыш, балалар саулыгына һәм җәмәгать урыннарында җәрәхәт алуга бәйле шалтыратулар да күп булган. Аның каравы юллардагы бозлавык аркасында егылып имгәнүчеләр саны кимегән. Мәсәлән, гыйнварның беренче атнасында 57 тапкыр мөрәҗәгать итсәләр, узган ел ахырында мондый шалтыратуларның саны 147 булган.

Гаиләләрдә

Билгеле, озын яллар күңелсез вакыйгалары белән генә истә калмады. Якыннар, туганнар белән очрашу, аралашудан алган матур кичерешләр белән бергә сөенечле вакыйгалары да җитәрлек булды. Әйтик, озын ялларда кайсыдыр гаиләләр сабый туу шатлыгын кичерде. Аждаһа елының беренче көнендә республика халкы 60 кешегә ишәйде. Яңа елны котлап аваз салган сабыйларның 32се малай булса, 28е – кызлар. Беренче бала Чаллыда туган. Аңа Идел дип исем биргәннәр. Бер атна эчендә Казанда 117 сабый дөньяга килгән.

Җәмәгать урыннарында

Яңа ел табынына әзерләгән сый-нигъмәтләр белән сыйланып, йокыларын туйдыргач, халык кабаттан кибет, сәүдә үзәкләре, базарларга юл алды. Бу юлы инде кием-салым артыннан. Алар акча янчыкларын бушатса, сатучылар мөмкин булганча табыш кертеп калырга тырышты.

– Без инде 2 гыйнвардан бирле эштә, – диде «ВТ» хәбәрчесенә кием-салым һәм аксессуарлар кибетендә эшләүче менеджер Айгөл Ибраһимова. – Ел ахырында һәм бу ял көннәрендә кибеттән кеше өзелмәде. Яңа елга кадәр бүләкләр алсалар, быел башлыча кием-салым сайладылар. Озын ялларда сату 60 процентка артты. Шуңа күрә без бик канәгать.

Бәйрәм көннәрендә акча эшләп калырга тырышучылар арасында кинотеатрлар да бар. «Интерфакс» басмасы хәбәр итүенчә, Яңа ел каникулы вакытында Россия кинотеатрларына 14,8 млн кеше барган һәм 5,8 млрд сумга билет сатып алган. Узган ел белән чагыштырганда, бу 1,3 млрд сумга күбрәк, дип хәбәр иткән Россия мәдәният министры Ольга Любимова.

Көне билгеле

Быелгы бердәм дәүләт имтиханнары расписаниесен раслаганнар. Россия Юстиция министрлыгы бу җәһәттән документларны теркәгән дә инде.

Шулай итеп, чыгарылыш сыйныф укучылары 22 марттан 22 апрельгә кадәр имтиханны вакытыннан алда бирә алачак. Төп чоры – 23 майдан 1 июльгә кадәр, ә өстәмә чоры – 4 сентябрьдән 23 сентябрьгә кадәр. 23 майда география, рус әдәбияты һәм химия буенча имтиханнар үткәрелә. Рус теленнән БДИ – 28 майда, математикадан – 31 майда. Җәмгыять белеменнән дәүләт имтиханын – 4 июньдә, тарих һәм физика фәннәреннән – 10 июньдә, биология һәм чит телләрдән (язмача өлешен) 13 июньдә бирәчәкләр. Информатика буенча БДИ – 7 һәм 8 июньгә, чит телләрнең телдән өлеше 17–18 июньгә тәгаенләнгән. Ә инде имтиханны нигезле сәбәпләр белән вакытында тапшыра алмаганнар өчен 20 июньнән 1 июльгә кадәр барлык фәннәр буенча резерв көннәр билгеләнгән.

Тугызынчы сыйныфлар өчен төп дәүләт имтиханы (ОГЭ) 21 май – 2 июль чорында уздырылачак. Вакытыннан алда имтиханны тапшырырга теләүчеләр өчен 23 апрельдән 18 майга кадәрге чор күздә тотылган. Өстәмә көннәр 3–24 сентябрьгә билгеләнгән.

Бер елда – 19

Узган елда Татарстанда 19 мәчет ачканнар. Алар Чүпрәле, Актаныш, Әлмәт, Питрәч, Әтнә, Яңа Чишмә, Арча, Ютазы, Алабуга, Балык Бистәсе, Азнакай, Мөслим, Балтач районнарында һәм Казанның 4 районында пәйда булган.

Диния нәзарәте хәбәренә караганда, яңа төзелгән Аллаһ йортларында, намаз уку өчен мәйданчыктан тыш, уку бүлмәләре, мәҗлесләр үткәрү өчен заллар, ашханә, никахлашу үзәкләре, кибетләр, корбан чалуны оештыру һәм җеназа үткәрү урыннары, имам йорты да булдырылган.

Бүгенгә республикада барлыгы 1582 мәчет эшләп килә. Узган ел азагында Казанда Росгвардия батальоны хәрби шәһәрчегендә дә кечкенә генә Аллаһ йорты ачканнар. Аның биеклеге – 2,5 метр, ә гомуми мәйданы – 15 квадрат метр.

Өчьяклы һөҗүм

Россиядә бер үк вакытта өч төрле чир – грипп, коронавирус һәм ОРВИ тарала. Белгечләр әйтүенчә, тридемиянең башлануы турында сөйли бу. Ул февраль – март айларында гына сүрелә башлаячак.

«Известия» хәбәренә караганда, хәзерге вакытта грипп ияртүчеләр саны көннән-көн арта. Чирләүчеләр саны 10 мең кешегә 128,1 очрак (нормадан 83 процентка зуррак) туры килә.

Шул ук вакытта яңа елның беренче атнасында илдә коронавирус йоктыруның 25922 очрагы (алдагы атнадагыга караганда 56,8 процентка азрак) теркәлгән. Татарстанда да ковид белән авыручылар саны кимегән: 1–7 гыйнвар көннәрендә 1149 кешедә (алдагы атнадагы белән чагыштырганда 22,5 процентка кимрәк) чир ачыкланган.

Суыклар сыный

Республикада атна ахырына кадәр суык булачак. Ә ял көннәренә таба кар-буран да өстәләчәк.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, пәнҗешәмбе – 11 гыйнварда көндез термометрның терекөмеш баганасы –14...–19 градус, көнчыгыш төбәкләрдә –22 градус күрсәтәчәк. Төнлә –24...–29, урыны белән –34 градус. Республиканың көнбатыш төбәкләрендә буран булачак.

Җомга – 12 гыйнварда көндез һава температурасы –10...–15, төнге сәгатьләрдә –16...–21 градус чикләрендә тирбәләчәк. Буран, секундына 15–20 метр тизлектә көчле җил, юлларда – кар көртләре. Шимбә – 13 гыйнварда температура көндез –18...–23, төнлә – урыны белән –30 градуска кадәр төшәчәк.

Синоптиклар, һава салкынаю сәбәпле, 10–15 гыйнварда кисәтү игълан иткән. Бу чорда тәүлеклек уртача температура –18...–24 градус тәшкил итәчәк. Нормадан 9–15 градуска түбәнрәк күрсәткеч бу.

Коткаручылар суыкта саклык чараларын күрергә: бик кирәк булмаганда, шәхси машинага утырып, табигатькә, урманга, балык тотарга бармаска, йорт-подъездларның җылылыгын кайгыртырга, балаларның ялгызы гына урамда йөрүләренә, мичләрнең артык кызуына юл куймаска, кулдан эшләнгән мичләрдән файдаланмаска киңәш итә.

Борчыган мәсьәлә

Уйлап җыйдырасы

Теләсә кайда җыйдырырга ярамый! Россия Эчке эшләр министрлыгы белгечләре, мошенниклар корбаны булмас өчен, тагын бер киңәшне истә калдырырга өнди. Эре сәүдә үзәкләрендә, җәмәгать урыннарында телефонга зарядка җыйдыру куркыныч, дип кисәтә алар.

Билгеле булганча, бүген кеше күпләп йөри торган җирләрдә телефон, планшет ише гаджетларга зарядка җыйдыра торган махсус урыннар пәйда булды. Бер яктан бу бик уңайлы. Телефон сүнеп, элемтәсез калсаң да куркасы юк. Гаджетыңны шушы махсус өстәлдәге чыбыкка тоташтырасың да вәссәлам! Әмма белгечләр әйтүенчә, шушы чыбык аша телефонга зарарлы программа, вируслар да эләгә ала. Шул рәвешле мошенниклар кешенең телефонындагы шәхси мәгълүматларына ия булырга, хәтта онлайн банк аша картадагы акчаларын да алырга мөмкин, дип кисәтә хокук сакчылары. Яңа ел ялларында Волградта ике кеше шул рәвешле мошенник корбаны булырга өлгергән инде.

Мондый аяныч хәлдә калмас өчен, берничә кагыйдәне истә тотарга кирәк:

– Телефоныгызны үзегезнең USB-чыбык ярдәмендә генә «туклandyрырга» тырышыгыз. Юлда чакта телефонга зарядка җыйдыру өчен кулланыла торган портатив җайланманың (повербанк. – **Ред.**) да билгеле фирманыкын гына кулланыгыз.

– USB-чыбыкны төрле максатта кулланырга мөмкин. Телефонны зарядкага кую өчен исә аның нәкъ менә шушы максатка билгеләнгәнен генә файдаланырга кирәк. Алар аша телефонга һәм телефоннан бернинди мәгълүмат та йөкләтеп булмый.

– Юлда табылган, чит кешедән алынган чыбык ярдәмендә телефонны «туклandyру» да хәтәр.

– Әгәр USB-чыбыкка тоташуга, телефонга ниндидер программа йөкләтергә рөхсәт сораган смс-хәбәр килсә, аны шундук өзегез.

Сүз уңаеннан, күптән түгел Саклык банкы ясалма интеллект ярдәмендә мошенниклар эзенә төшүнең яңа ысулын тапкан. Шул рәвешле банк хезмәткәрләре исеменнән шалтыратып, халыкны төп башына утырткан шактый кырыгалдарның эзенә төшкән алар. Ялган колл-үзәкләрнең берсе Казанда урнашкан булган. Җинаятьчел төркемдә 17 кеше исәпләнгән.

Сүзгә-сүз

Иван ЯЩЕНКО, Өзлексез математика белеме бирү үзәге директоры, математика буенча БДИ биремнәрен эшләүче комиссия җитәкчесе:

Дәрес алып барганда һәм өй эшен биргәндә укытучы бала тормышындагы иң кадерле мизгелләрне – бәхетле балачак минутларын сарыф итә. Ул бу хакыйкатьне беркайчан да исеннән чыгармаска тиеш.

(«Российская газета»дан)

ТАТАРСТАНДА – ТРАНСПЛАНТОЛОГИЯ

485 кешенең гомерен саклап калганнар

Бөер күчереп утырту – 279 операция (2023 елда – 115)

Бавыр күчереп утырту – 166 операция (2023 елда – 72)

Йөрәк күчереп утырту – 40 операция (2023 елда – 26)

*Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына таянып



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

2024 ЕЛНЫҢ ДАВЫЛЛЫ СТАРТЫ

Ел мантыйкый рәвештә зур тетрәнүләр белән башланды. Гыйнвар старты елның табигый бәла-казаларга, социаль тетрәнүләргә, дәүләтләр арасындагы конфликтларга мул булачагын вәгъдә итә. Яңа елны зурлап каршы алу японнарга булышмады: 1–2 гыйнвар көннәрендә илдә төрле куәттәге 521 җир тетрәү теркәлде. Иң көчле тетрәүнең магнитудасы 7,6 баллга тигез булды. Җир тетрәү нәтиҗәсендә 5 метрга кадәр биеклектәге цунами котырды. Ике йөзләп йорт җимерелде, ун меңләп йорт – сусыз, 7,8 мең йорт утсыз калды.

Җир шары Кояш тирәли яңа әйләнешен башлап та өлгермәде, Төньяк һәм Көньяк Кореялар арасында зур сугыш кабыну куркынычы пәйда булды. Урын аз булганлыктан, конфликтның үсеш этапларын шәрехләп тормыйбыз, ике илгә сүз генә бирәбез. Төньяк Корея лидерының кыз туганы Ким Ё Чжон: «Тагын бер тапкыр кабатлыйм: безнең армия инде тәтене саклагычтан алды. Кечкенә генә провокациягә дә безнең гаскәрләр кичекмәстән ут белән «чукындырып» җавап бирәчәк», – дигән белдерү ясады. Көньяк Корея телевидениесе, агымдагы вазгыятьтән репортаж тапшырып, сугышка әзерлекнең финиш сызыгында булуын күрсәтте. Әмма хәл никадәр генә киеренке булмасын, бу юлларның авторы сугыш башлану ихтималы бик кечкенә дип бәяли. Ике илнең узара ут уйнатуы – традиция инде ул, әмма беркайчан да хәл буразлашуга барып җитми.

Иранда америкалылар тарафыннан үтерелгән генерал Сәләймани җирләнгән каберлек янында канлы террор акты да сугыш китереп чыгарырга ихтимал дип көткәннәр иде. Тәһран террорны оештыруда Америка һәм Израильне гаепли, ИГИЛ*ның гаепне үз өстенә алуын ясалма дип бәяли. Фарсылларның Җәмкаран мәчете гөмбәзенә кызыл флаг күтәрүләрен (үч алу символы дип санала) шулай ук сугышка юрыйлар. Әмма эш зурга китмәс. Якын Көнчыгыштагы Израиль башбаштагы туктатылмаса, бөтен дөньяга кайтаваз бирәчәк төбәк сугышы бөтенләй башка сценарий белән барыр. Без, мөгаен, конфликтның озакка сузылган һәм акрын әйләнешле үсешен күзәтербез.

Кытайда кызыклы хәлләр булып ята. Алар үзләре бик сиздерергә теләмәсә дә, ил икътисадында эшләр шәп түгел. Японнар, мәсәлән, кытай түнтәрелешен бик куркып күзәтәләр, чөнки аларга да сугачак. Менә шул фонда Кытай армиясендә югары җитәкчелекне массакүләм кыгла алулар бара. Генераллар коррупциягә баткан, диләр. АКШ разведкасы соңгы көннәрдә генә Кытай ракеталары ягулык урынына су белән тутырылган дигән сенсацион белдерү ясады. Хәрби җитәкчелек ягулыкка дигән акчаны кесәгә салган дигән сүз бу.

Киеренкелек дөньяның башка почмакларында да үсә, әмма аларны сөйләргә урын калмады.

* Россиядә эшчәнлеге тыелган оешма

Россиядә

ТАВЫК ИТЕ БЕТӘМЕ?

Дөньякүләм турбулентлык Россиядә дә үзен сиздерә. Без берничек тә глобаль тетрәүләрдән читтә кала алмыйбыз. 2024 елның беренче сәгатьләре башланып кына өлгерде, мәгълүмат кырында Россиянең берничә төбәгендә тавык ите дефициты күзәтелә дигән хәбәр тарала башлады. Андый хәбәрләр ялган булса да, тиз чыннга аша, чөнки ажиотаж тудыра. Ажиотажга бер базар да каршы тора алмый. Газета хәбәрчесе, дефицит турындагы яңалыкны куруә, «Ватсап»тан Свердловск өлкәсендәге танышларына сорау юллады. «Тавык ите бар, беркая да китмәде», – диделәр уралллылар иртәнге якта беравыздан. Әмма кичкә кытлык башлануын, тавыкларның каядыр очып юкка чыгуын расладылар. Суыклар булу сәбәпле, продукциянең кибетләргә вакытында китерелеп җиткерелмәве, дефицит шул сәбәпле барлыкка килү турында рәсми игълан булды. Эпопея үсешен дәвам итәрме – анысын алдагы көннәрдә күрербез.

Илнең инфраструктурасы тузган. Коммуналь хуҗалыкта 2024 елның беренче суыклары китереп чыгарган проблемалар шул хакта сөйли. Сер түгел: күп кенә Россия төбәкләрендә су һәм җылылык совет чорыннан калган торбалар аша килә. Алар тузды инде. Шул сәбәпле тармакта аварияләр саны арту күзәтелә. Без, Росстат мәгълүматларына таянып, нәтиҗә ясыйбыз, фактны бармактан да суырмыйбыз. Росстат белдергәнчә, коммуналь хуҗалыкның тузу күрсәткечләре үсә, ә янартылу коэффициенты кими.

Гыйнварның санаулы көннәре дә узмады, Мәскәү янындагы Подольск, Химки, Наро-Фоминск һәм башка торак пунктларда зур аварияләр булып, йортлар туңды. Башка төбәкләрдә дә күзәтелде андый хәлләр. Волгоград, Екатеринбург, Ленинград өлкәләрендәге кайбер йортларда халык, бәйрәм итәсе урынга, җылы сыену урыны эзләде.

Федераль хөкүмәт коммуналь хуҗалыкны яңарту өчен байтак акча бүлеп бирүен әйтә, әмма әллә финанслау барыбер җитәрлек булмаган, әллә акча тиешле адресларга барып җитмәгән, хәл киеренке. Мәсьәләнең борчый торган бер ягы бар: бюджетта коммуналь хуҗалыкны үстерү өчен чыгымнар елдан-ел кимүгә бара. 2023 елда 856 миллиард сум каралган булса, 2024тә – 818 миллиард кына, 2025тә – 455 миллиард, 2026да – 360 миллиард сум.

Проблема югарыга таба үскәндә, финанслау түбәнгә китә алмый. Мөгаен, федераль бюджет, Милли резерв фонды капчыгын чишеп, өстәмә финанслауга күчәрдер.

САЙЛАУ – 2024

ИМЗАЛАРНЫ КЫШЫН САНЫЙЛАР

Казаннан Мәскәүгә Владимир Путин кандидатурасын хуплап җыйган тәүге имзаларны илтеп тапшырдылар. Эш исә дәвам итә. Исегезгә төшерәбез: имзаларны гыйнвар азагына кадәр җыячаклар. Ул арада Үзәк сайлау комиссиясе бу елның мартында узачак сайлауда Россия Президенты вазыйфасына беренче кандидатларны теркәдә инде.

putin2024.ru

Мәгълүм булганча, Владимир Путин кандидатурасын хуплап имза җыю узган елның декабре ахырында башланды. Ул гыйнвар ахырына кадәр дәвам итәчәк. Әлеге эш республикадагы төрле шәһәрләрдәге зур сәүдә үзәкләре, кандидатның төбәк штабы, Халык фронтының төбәк бүлекчәләре кебек урыннарда оештырылган. Әлегә Татарстаннан күпме имза җыелуы турында төгәл мәгълүмат та юк. Бу хакта эш беткәч кенә әйтәчәкләр.

– Татарстанда яшәүчеләр Владимир Путинның үзен үзе Президент вазыйфасына тәкъдим итүен хуплый. Волонтерлар, «Бердәм Россия» партиясе активистлары, Халык фронты ярдәме белән имзалы кәгазьләр күп җыелды. Әлеге эш алга таба да дәвам итә, – ди имзалар куелган кәгазьләрне Үзәк штабка тапшыруда катнашкан Россия Герое Рәсим Баксиков. – Илебез даими үсештә. Владимир Путин бу эш белән 2000 елдан бирле шөгыльләнә.

Владимир Путинның сайлау сайтыннан алынган мәгълүматларга караганда, ил төбәкләреннән, гамәлдәге Илбашын хуплап, 1 миллион 300 меңнән артык имза җыелган инде. Барлыгы 60ка якын төбәктән имза куелган тәүге кәгазьләр килеп ирешкән. Аларны тикшерү һәм санау ай азагына кадәр дәвам итәчәк.

Имзаларны үзебездә дә энә күзеннән үткәрәләр. Президентның вышанычлы заты, Гомумроссия Халык фронтының Татарстандагы төбәк башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Фазылов искәрткәнчә, имза куелган барлык кәгазьләрне дә юристлар тикшерә һәм аларны ышанычлы зат раслый. Аерым алганда, юрист кәгазьләрнең дөрес итеп тутырылуын карый. Мәсәлән, имза чикләрдән чыгып киткән, паспорт мәгълүматлары төгәл күрсәтелмәгән икән, мондый кәгазьне кабул итмиләр.

Илнең башка төбәкләреннән аермалы буларак, Татарстанда имза җыю эшендә яшьләр дә бик теләп катнаша икән. Бу хакта «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Төбәк башкарма комитеты җитәкчесе Марат Сәмигуллин әйткән. «Нәкъ менә безнең республикада имза җыюда яшьләр активлык күрсәтә. Мондый хәлне көтмәгән дә идек», – дип сөйләгән ул.

Бу елның мартында узачак сайлауда тәгаен катнашачак тәүге кандидатлар билгеле инде. Алар – өч кеше. Яңа ел бәйрәмнәре арасында ук Үзәк сайлау комиссиясе ЛДПР җитәкчесе Леонид Слуцкий һәм Дәүләт Думасы вице-спикеры, «Новые люди» партиясе вәкиле Владислав Даванковны, ә бәйрәмнәрдән соң, КПРФтан Николай Харитоновны рәсми рәвештә кандидат буларак теркәде. Сүз уңаеннан шунысын да искәртик: парламент партияләреннән кандидатларга имза җыярга кирәкми. Соңгы мәгълүматларга караганда, быелгы сайлау кампаниясендә Илбашы вазыйфасына унбер кеше: төрле партияләрдән – сигез һәм үзен үзе тәкъдим итүче өч кандидат дәгъва кылырга җыена. Президент сайлау өч көн – 15, 16 һәм 17 мартта узачак.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Ватан хакына

Солдатларга ярдәмгә

Безнең ярдәм бик кирәк. Мөслим районының Метрәй авылы егете Рүзәл Минһаҗев махсус хәрби операция башланганнан бирле Ватан сагындагы егетләргә ярдәм оештыра. Егетләр янына 13 тапкыр барып кайткан инде ул. Әле менә тагын ерак юлга кузгалырга җыена.

– Солдатларга нәрсә кирәк – шуны илтәбез. Мәрхәмәтле кешеләргә рәхмәт. Машиналар да, аңа кирәкяраклар да, җылытקыч, окоп шәмнәре, җылы оекбаш, тәмле күчтәнәч алар көче белән җыела, – ди ул.– Балалары, ирләре, әтиләре хәрби операциядә катнаша торган гаиләләргә бик авыр. Шуңа да Яңа ел алдыннан, әтиләре Ватан өчен һәлак булган һәм хәзер махсус хәрби операциядә катнаша торган сабыйлар янына барып, күңелләрен күрергә тырыштык. Илебезгә килгән хәсрәт. Безгә бердәм булырга, егетләр тизрәк өйгә кайтсын өчен кулдан килгәнне эшләргә кирәк.

Шушы көннәрдә Арча районы хәзрәтләре махсус хәрби операция зонасындагы солдатларга броньланган «ГАЗель» машинасы сатып алган. Арча районы имам-мөхтәсибе Әмир хәзрәт Миңнемуллин «ГАЗель»нең ачкычын Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга тапшырды.

– Әлеге машина солдатларны госпитальгә озату, азык-төлек, су, медикаментлар илтү өчен файдаланылыр дип көтелә. Якын арада машина махсус хәрби операция зонасына озатылачак, – ди район мөхтәсибе Әмир хәзрәт Миңнемуллин.

Казанның Вахитов һәм Идел буе районы башлыгы Альберт Салихов та егетләр өчен «Нива» машинасы җибәрүләрен хәбәр итте. Әлеге машинаны 1231 нче полк егетләренә дип, «Фестрал» оешмасы директоры ярдәме белән сатып алганнар.

– Машина егетләргә кирәк булганча җиһазландырылды, техник күзәтү үтте. Салкыннарда җылытсын дип, егетләребезгә үлән чәйләре белән бал да җибәрдек, – ди Альберт Салихов.

Чаллы мэры Наил Мәһдиев тә якташ егетләргә бәйрәмнәрдә күчтәнәч җибәрүләрен хәбәр итте.

– Ял көннәре дип тормадылар, Чаллыда яшәүчеләр егетләргә күчтәнәч әзерләде. Госпитальләргә һәм солдатларга кирәк-ярак җибәрдек. Бу тагын бер мәртәбә безнең бердәмлекне исбатлады, – ди мэр.

Әлмәттә һәр авыл җирлеге махсус хәрби операциядә катнашучы егетләрнең гаиләләрен кайгыртә.

– Бер генә гаилә дә читтә калырга тиеш түгел. Моңа кадәр ничек эшләдек, хәзер дә шулай булыйк. Батыр егетләрнең гаиләләре үзләрен кайгыртуны тоярга тиеш. Нинди генә сораулары булса да, хәл итәргә кирәк, – дигән район башлыгы Тимур Нагуманов.

Мамадышта яшәүче Юрис Шәкүровны солдатларга мунча ясап җибәрүче буларак беләләр инде. Ялларда ул тагын изге эш башкарган. Махсус хәрби операциядәге һәм анда һәлак булган якташларының сабыйларын җыеп, үз өендә чыршы бәйрәме уздырган. Әнә шулай итеп, балаларның күңелен күргән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татмедиа» акционер җәмгыяте филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» генераль директоры **Әскәров** Әнәс Тәлгать улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлек башлыгы **Мортазина** Диләрә Илдар кызына Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

tatar-inform.ru

САЛКЫН ЯЛЛАР

Хәтерләсәгез, озын-озак ялларда Татарстанда узачак мәдәни һәм күңел ачу чараларын барлаган идек. Яллар тәмам, нәтиҗә ясар вакыт җитте. Салкыннар кемнәргә һәм нәрсәгә комачаулаган? Кем күпме кунак кабул иткән? Татарстан Хөкүмәт йортында узган 2024 елның беренче брифингында әнә шул һәм башка сорауларга җавап бирделәр.

Районнар

Башкалага кадәр район һәм авылларны әйләник. Быелгы ялларда Татарстан районнарында барлыгы 6,5 мең чара узган, ул чараларны 800 мең кеше тамаша кылган. Татарстан мәдәнияте министры Ирада Әюпова сүзләреннән аңлашылганча, чаралар саны да, кеше саны да узган елгыдан ике мәртәбә диярлек арткан.

– Әчтәлек ягыннан да үзгәрешләр бар: районнарыбызда гадәти чыршы бәйрәмнәреннән тыш музыкаль кичәләр, концертлар, күп төрле остаханәләр узды, күргәзмәләр эшләде. Әлбәттә, Яңа ел – беренче чиратта, гаилә бәйрәме. Шуңа да төп игътибар гаилә чараларына юнәлтелгән иде, – дип сөйләде министр.

Район һәм шәһәрләрдәге музейлар да шактый кунаклар кабул иткән. Әйтик, Зөя утрау-шәһәрчегендә Яңа ел ялларында 45 меңгә якын кеше булган. Алабуга музей-тыюлыгы – 8,5 мең, ә Болгар музей-тыюлыгы 6,7 мең кунак кабул иткән. Чистайдагысына исә 3,2 мең кеше барып кайткан.

Башкала

Казанда исә яллар дәвамында иң күп кунакны Казан Кремле кабул иткән.

– Казан Кремлендә үткән чараларны 195 меңнән артык кеше тамаша кылган. Тамашачылар саны буенча лидерлар рәтендә – Казан циркы (86 мең), Зөя музей-тыюлыгы (44,87 мең), «Әкият» курчак театры (29,88 мең) һәм Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе (18,83 мең), – дип сөйләде Ирада Әюпова.

Бәйрәм ялларында Казанда чараларсыз бер генә көн дә узмады, дисәк, бераз гына арттыру булачак. Чөнки парк һәм скверлардагы чараларның кайберләрен уздырырга салкыннар комачаулады.

– Ачык һавада барлыгы 180ләп чара узарга тиеш иде. Унысын кучерергә, өчесен уздырмый калырга туры килде, – дип сөйләде Казан башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов.

Сүз уңаеннан, шәһәрдәге бәйрәм бизәлеше һәм чыршыларны әлегә кадәр күрмәгән булсагыз, 14 гыйнварга кадәр вакытыгыз бар. Азат Абзалов хәбәр иткәнчә, аларның барысын да искечә Яңа елдан соң гына сүтә башлаячаклар.

Елдагыча, озын яллар читтән килгән кунакларны кабул итү өчен дә яхшы форсат булды. Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов сүзләренчә, бу ялларда Татарстан җәмгыясы 170 меңләп турист кабул иткән.

– Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырсак, бу – 5 процентка күбрәк дигән сүз. Әлеге җәһәттән М12 түләүле трассасын да билгеләп үтәргә кирәк. Аннан да туристлар агымы килә башлады. «Татарстанга килү хәзер тагын да тизрәк һәм рәхәтрәк», – диләр кунаклар, – дип сөйләде Иванов.

Аның сүзләренчә, туристларның күпчелеге Мәскәү, Мәскәү өлкәсе һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән килгән. Алар арасында Арчадагы Кыш бабай резиденциясе, Раифа монастыре, Балык Бистәсендәге «Дикая ферма» эко-парклы, балык тоту базалары, тау чаңгысы комплексларя аеручa популяр булган.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Оятка кала яздым

«Ватаным Татарстан» газетасында эшләп йөргән чакларым. «Ишегем ватылды, ябылмый, рәтләп кенә бир әле!» – дип, корректор Лена Шагыйрьҗан мине өйләренә чакырды. Бардым, карадым. Ишеккә яңа йозак куярга туры килде. Лена апа әйбәтләп сыйлады, кайбер сыйнигъмәтне төреп, җир җиләге компотын шешәгә тутырып бирде. Редакциягә кайтып, эшкә кереп барганда карыйм: баш мөхәррир Мөнир абый Әһлиуллин журналистлар Мөнир абый Абдуллин, Нургали абый Булатов белән коридорда сөйләшеп тора. Лена апа биргән күчтәнәчләр кулдан ычкынып китеп, идәнгә чәчелде, шешә исә челпәрәмә килде.

И-и шунда мөхәрриребез рәхәтләнеп көлде инде, үзе шаяра, үзе көлә. Яхшы күңелле, миһербанлы хезмәттәшләремә бәйле шул мизгелне һаман да сагынып искә алам.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН

Кар яуды

Менә нинди кар яуды:
Ап-ак булды җир өсте.
Чаналарга, чаңгыларга
Җиткереп булмый эшне.

Бөтен дөнья чаж да чож,
Тауда – тау шуучылар.
Тау асты да чуп-чуар,
Тау өсте дә чуп-чуар.

Тау башыннан төшкәндә
Мәтәлеп тә китәләр.
Ничек итсә-итәләр,
Барыбер төшеп җитәләр.

Гел шома гына булмый шул,
Кайчакта егылалар.
Егылсалар егылалар,
Алар бит чыныгалар.

Галимҗан ЛАТЫЙП

Илдар Мөхәммәтҗанов

МӘКТӘБЕМ – БӘЛЛҮР БИШЕГЕМ

Үткән елның декабрь аенда Социалистик Хезмәт Герое Камил Шакиров исемендәге Зур Сәрдек урта мәктәбенең (хәзер гимназия статусында) 110 еллыгын бәйрәм иттек. Шатланып, горурланып әйтәбез: белем һәм тәрбия бирүдә милли гореф-гадәтләргә ныклап таянган, республика мәгарифендә лаеклы урынын булдырган, «Татарстанның иң яхшы 100 мәктәбе» исемлегенә кертелгән, башлангыч чорда Сәгыйть Сүнчәләй җитәкчелек иткән белем йортыбыз ул.

Зур Сәрдектә урта белем алганнар исә, кайсы гына тармакта хезмәт куйсалар да, мактаулы, үрнәк, тел-теш тидерерлек түгелләр. Орден-медальләргә, мактаулы исемнәргә, дәрәҗәләргә лаек булучылар исемлеген хәтердә яңарту өчен генә дә хәтсез вакыт кирәк булыр иде. Заманында Зур Сәрдек мәктәбендә урта белем алган егетнең укуын Мәскәүдә Ломоносов исемендәге университетта дәвам иттерүе дә күп нәрсә хакында сөйли. Очрашуга кайткан мәктәптәшләребез дә һәр чорда яхшы белем-тәрбия бирелүе турында горурланып сөйләделәр, мөгаллимнәрне, мөгаллимәләрне тирән хөрмәт белән искә алдылар, рәхмәтләрен җиткерделәр.

«Мәктәпнең укытучылары нинди, укучылары да шундый» дигән әйтем бу урында бик тәңгәл килә. Укучыларыбыз белемле, бик сәләтле. Олимпиадаларда, гамәли конференцияләрдә, иҗади бәйгеләрдә, спорт ярышларында алар – призлы урыннарда. Укучылар һәм укытучылар өчен Сәгыйть Сүнчәләй исемендәге фәнни-гамәли конференциянең гамәлгә куелуы да табигый, Казан федераль университетының татар теле бүлеге белән берлектә «Хәзерге җәмгыятьтә туган телләр» дип исемләнгән конференция өстәлү, нәфис сүз бәйгеләре белем йортының дәрәҗәсен тагын да үстерде. Укучыларыбыз әлеге чараларда эзләнү, белем эстәү алымнары белән уртаклашалар, беренчел чыныгу алалар, фикердәшләр, теләктәшләр, дуслар табалар.

Бу уку елында гимназиядә 319 укучы исәпләнә, аларга 47 педагог белем, тәрбия бирә. Җирлектәге өч башлангыч мәктәп тә гимназиянең филиаллары буларак, нәтиҗәле эшләп килә. Укытучыларыбызның җитмеш проценты квалификация категорияләренә ия, үзләре сайлаган һөнәргә тугрылыклы, тәҗрибә туплаган буын.

Шәхсән мин үзем дә шушы гимназиядә белем алдым, тормыш иминлеге нигезләре, технология укытучысы булып эшләдем, җитәкчелек дилбегәсен алуыма әле күп вакыт үтмәде. Бай тарихлы белем йортында бу вазыйфага алынуның никадәр җаваплылык икәнлеген яхшы аңлыйм. Шунысы куандыра: без остазларыбызның, район җитәкчелегенең ярдәмен һәрдаим тоеп яшибез, бу инде эшкә дәрт-дәрман өсти. 110 еллык юбилей алдыннан гимназиябез бик нык яңартылды. Районыбыз җитәкчесе Сергей Димитриевның ремонтны федераль программага кертү мәшәкатьләре белән йөрүенең нәтиҗәсе һәм сөендергәне шул: гимназиягә 135 миллион сумлык ремонт ясалды, белем бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, бүлмәләребез өр-яңа, җиһазлар да заман таләпләренә җавап бирә. Кукмара муниципаль районы башлыгы да, район мәгариф идарәсе дә төзекләндерүнең барышын көндәлек контрольдә тоттылар, аларга рәхмәтебез чик-чамасыз. Юбилей очрашуына кайткан элеккеге шәкертләребез дә белем йортының яңартылуына соклануларын яшермәде, хәтер яңарды, киләчәккә якты өмет багланды.

Мәгариф тармагында эшләүчеләргә заман зур бурычлар куя. Коллектив җаваплылыкны тулысынча аңлый, димәк, киләчәгебез өметле. Мәктәп тарихын бүгенге укучылар һәм укытучылар күркәм эшләр белән дәвам иттерә.

Руслан БАҺАВИЕВ,
Кукмара районы Зур Сәрдек гимназиясе директоры

«Әти бит, ничек ышанмыйсың...»

Бу дөньяда balаңнан якын, балаңнан кадерле берни дә юк. Кырык яшендә дә, илле яшендә дә ул әти-әни өчен – «балакаем». Кирәк икән, алар синең өчен авызыннан өзеп, соңгысын бирергә әзер. Һәм бирә дә... Өен, фатирын оныгына яисә баласына яздырып, картлар йортына килеп эләккән әби-бабайларны заманында шактый күрдем. Алар туган йортларын өзелеп сагынса да, беркайчан зарланмас. «Балага шулай кирәк булды, аның башка чарасы калмаган иде...» Сораштыра башласаң, гомерләрен тәрәзә янында кемнедер көтеп үткәргән ул бәхетсезләр шундый сүзләрдән башка артыгын сөйләмәс. Шуңа да әниләр, шуңа да әтиләр бит алар!

...Моннан бик күп еллар элек, йомышым төшеп, хәйрия фондына баргач та ишеткән идем мин бу сүзләрне. Йөрәк өзгеч ул вакыйгаларга кагылырга куркыпмы, «кеше алдында оят» булудан хурланыпмы, башта ханым шактый вакыт «белмим, белмим», дия-дия икеләнеп торды. «Исән бит әле ул, миңа, балаларыма зыян салырга мөмкин...» – дип, алдагысы өчен борчылуын әйтте. Шулай да ул сөйлисе итте. «Гыйбрәт өчен», – диде. Тын да алмый аны тыңлыйм. Ишеткәннәремә ышанасы килми, күңел кабул итми. Ничек инде?

– Әйе, ничек инде? – ди кырык яшендә күрмәгәне калмаган, бөтен борчу-хәсрәтләрне кичерергә өлгергән ханым. – Күрәчәк булгандыр инде. Авырлыкның ни икәнен балачактан ук татыдым. Мин өч балалы гаиләдә үстем. Әти белән әнинең тату яшәгәнен хәтерләмим: гел тавыш, гел талаш... Алар безнең кичерешләрне санга да сукмадылар. Көннәрдән бер көнне әти безне ташлап чыгып китте. Дөресрәге: «Урнашыйм да кайтып алырмын», – дигән булды. Шуннан юкка чыкты. Әни хастаханәдә чагында әти безнең өч бүлмәле фатирыбызны саткан. Ул заманында зур, дәрәҗәле эшләрдә эшләде. Аның сүзен тыңлыйлар иде. Шуңа нәрсә эшлисе килсә, шуны эшләде. Ул, безне урамда калдырып, үзе рәхәтләнеп яшәде.

... Аның тормышы куркыныч бер әкияткә охшаган. Әнисе аны яратмаган. «Әтиең кызы», – дип, бертуктаусыз кабатлап торган газиз әнкәсе аның эшләре белән бөтенләй кызыксынмаган. Хәтта, үзе әйтмешли, дошманы итеп күргән. Кимсетүләр, үз якыннары тарафыннан рәнҗетүләр, «шыксыз үрдәк бәбкәсе» хәлендә булулар чыгырдан чыгаргандырмы, бервакыт ул дүртенче кат тәрәзәсеннән сикерә. Исән кала. «Коляскага калыр», – дисәләр дә, аягына баса. Алай гына да түгел, спорт белән шөгыльләнә башлый. Ике мәртәбә кияүгә чыга. Беренче ире һәлакәткә очрап, вафат була. Икенчесе – аферист. «Түзә алмадым, баланы күтәрдем дә чыгып киттем», – ди ул тормышының авыр мизгелләренә кайтып. Иң ачысы, иң газаплысы шул мәлдән башлана. Хатын, ире белән аерылгач, ана капиталына искереп беткән бәләкәй генә өй сатып ала. Бәләкәй, әмма үзенеке. Ул шуңа да бик риза. Әкренләп рәтләр, төзәтер әле. Ләкин... бер сөйләшү аның бөтен тормышын астын-өскә китерә. Һич көтмәгәндә, ничәмә-ничә елдан соң, әтисе шалтырата. 25 ел күрешмәгән, сөйләшеп-аралашып тормаган әтисе! «Нигә шалтыратты икән?» дигән уй башына да килеп карамый. Каян телефонын тапкан?! Әти кеше моңарчы уена да кереп карамаган кызының хәлен сораштырган була. «Начар, эшем юк, аерылыштым, ирем алимент түләми. Утын белән җылытыла торган җимерек өйдә яшәп ятам», – ди ханым бу хакта сораштыра башлагач, еларга ук керешеп. Әти кеше кызын үзенә кунакка чакыра. Хәтта юлына акча да җибәрә әле. Ә кыз – күкнең җиденче катында. Ниһаять, әтисе аның барлыгын исенә төшерде. Аның янында узган ун көн кыз өчен онытылмас вакыйга була. Алар сөйләшә, серләшә. Әтисе аңа үзенең хәлләрен сөйли. Хатыны үлгән, ул ике баланы берүзе тәрбияләп үстергән. Кыз өенә кайтып киткәч тә ул гел аңа шалтыратып, хәлләрен белешеп тора. «Сиңа булышасым килә», – дигән була. «Әти бит, ничек ышанмыйсың...» – дип кабатлый хәзер ханым үзәгенә төшкән сүзләрне. Әти кеше кызын үз янына чакыра. Һәм ул, булган бар мөлкәтен – өен, машинасын сатып, әтисе янына күченеп килә. Баштарак әтисе үзен әйбәт тота. Дәрәҗәле эшләрдә эшләгән кешенең дүртәр бүлмәле ике фатиры, ике машинасы, җир участоклары була. Күченеп килгәндә ул кызына бер бүлмәле фатир алып бирергә вәгъдә итә. Кыз ышана. Чит кеше түгел лә ул аңа, үз әтисе. Ничек ышанмыйсың?! Тик озак та үтми, бөтен нәрсә үзгәрә дә куя. Бик каты эчкән әтисе аны: «Син – аферистка», – дип, баласы белән урамга куып чыгара. Шулай итеп, кара төндә ул баласы белән урамда кала. Кирәкле әйберләрен, документларын, машина саткан акчасын да алырга өлгерми ул. Хатын баласы белән хостелга урнашканнан соң, берничә көннән сумкасын китерәләр китерүен. Әмма инде акчасы да, хәтта алтын бизәнү әйберләре дә юкка чыккан була.

– Ничек инде? – дим, ишеткәннәремнән өнсез калып, – әти кеше шуны эшли аламы?

– Мин дә шулай уйлыйм, – ди ханым, баштан кичкәннәрен бер мәхшәргә тиңләп. – Ышандым мин аңа. Әти бит, ничек ышанмыйсың...

Шуннан бирле әти кеше араны бөтенләй өзә. Урамда япа-ялгызы калган кызының хәлен дә, ничек яшәгәнен дә белешми. Иң авыр чагында без кемгә таянабыз? Әлбәттә инде, исән-сау булганда, әти-әнигә... Ничек кенә булмасын, хәтта бу очракта да, кемгә таянганыңны бел, дип әйтергә тел әйләнми. Чөнки бу – дөньяда булмаган хәлләр исәбенә кергән куркыныч күренеш...

Мәдинә АВЗАЛОВА

Гаиләбез истәлекләреннән

УКУЫҢНЫ ТАШЛАМЫЙСЫҢ!

1980 нче еллар ахырында әнием кышларны Казанда уздыра башлады. Айдар энем, аның гаиләсе карамагында булды. Гомеренең соңгы елында әнием, Нәни апай ярты көн генә эшләргә карар кылгач, аның фатирында яшәде. Ул эштә вакытта әнием янында Айдар энем булды, бар кирәк-ярагын булдырып, кергәләп йөрде. Нәни апай яшәгән йорт Айдарларга бик якын иде. Ул елларда әнием янында мин Нәни апаем шикелле көне-төне була алмадым... Бакый Урманче музее «төзеп» йөрим... Җитмәсә, режиссерлыкка укыйм... Шулай беркөнне Нәни апайга әйтәм: «Бөтенләй әниемне карарга булыша алмыйм бит, эштән үз хисабыма отпуск алыйм, институтны да ташлыйм», – дим. «Нинди сүз ул! Әле андый хәлгә калмаган, Айдар белән мин аны кирәгенчә карыйм бит, – дип, Нәни апаем кырт кисте. – Укыйсың, ташламыйсың!»

...Мин килгәләп кенә йөрдем. Күп вакыт әнием белән телефон аша гына аралаштым. Ничә шалтыратсам да, ул миңа: «Хәлем әйбәт, кызым, миңа монда бик рәхәт», – ди торган иде. «Инде яз да җитә, тиздән авылга кайтырбыз», – дип яшәгәндә, йокларга яткан җиреннән дөньядан китеп барды...

...Әниемнең өчләрен, җиделәрен уздырган көннәребездә мин, елый-елый диплом эшен яклап, дәүләт имтиханнарын биреп йөрдем...

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

ХУҖАСЫНА ТУГРЫ АТ

Без малай чакларда исеме «Мелиорация» дип йөртелеп, яшелчәчелек буенча республикада данлыклы колхозның баш хисапчысы Мирхәтим абзый бар иде. Илленче еллардан соңгы бу чорда район үзәге Тымытыкка (анда заманында Никита Хрущев та булды) 3–4 көн саен исәп-хисап тотарга барып йөри иде ул. Төп транспорты тыпырдап торган чабышкы ат булды. Мирхәт (аны авылда шулай атап йөртәләр иде) ат заводыннан махсус кайтарылган бер айгырны сайлап ала. Ат караучы кодасы чабышкыны бик назлап, яхшы солыдан өзми, шуңа ат тыпырдап-биеп тора, аны матурлап-бизәп ясалган тарантаска җигеп, үзе кучер булып йөри дә, аннары ат Мирхәткә тәмам күнегә. Баш хисапчы айгырга «Китап» дип исем куша. Кайбер көннәрдә ат аны кышкы зәмһәрир суыкта, буранда булсынмы, көзге тәмам салкын яңгырларда да үзе тоемлап, капка төбенә үк кайтарып җиткерә – нәкъ «Кеше язмышы» фильмындагы әсирне коткарган ат кебек. Шул тиклем дә ияләшә Китап: Мирхәттән башка беркемгә дә баш ими, тоттырмый, Тымытык юлыннан тик аңа гына уйнаклап-биеп бара. Район үзәгендә баш хисапчы туктый торган фатир хуҗасы да атка солысын, хуш исле урман печәнен салып тәрбияли. Алмачуардай Китап Мирхәтим абзыйның килүен әллә кайдан кешнәп көтеп ала.

Ә беркөнне һич уйламаган җирдән Китап Мирхәтим абзыйның капка төпләренә гадәттәгедән бик кызу кайтып туктый. Кичке шәфәкъ иңеп килгән чак. Ат беркайчан да булмаганча сискәндергеч итеп кешнәп, хуҗа хатынны чакыра. Хатын тарантаста башын бер якка авыштырып, тынсыз-өнсез ятучы Мирхәтимгә төбәлә дә кычкырып җибәрә. Мирхәтим абзыйның бер яңагыннан чигә өлешенә кадәр кара янып, кан агып төшкән була. Тиздән участок инспекторы килеп җитә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мирхәтим абзыйны район сырхауханәсенә экспертизага алып киткәч, үтереп, тарантаска салып җибәргәннәр, дигән имеш-мимеш сүзләр белән кайтаралар да икенче көнне җирләп тә куялар. Тикшерүләр озак бара, әмма бернәрсә дә ачыкланмый.

Мирхәтим абзыйның вафатыннан соң Китап, сагышланып, чирләп, аяктан егыла, күзгә күренеп ябыга башлый һәм хуҗасының җидесен үткәргән көнне аякларын суза. Аны Мирхәтим абзыйның малайлары, күршеләре һәм баҗасы аерым урынга илтеп, зурлап күмеп кайталар.

Еллар үтсә дә, Мирхәтим абзый белән аңа җаны-тәне белән бирелгән тугры аты гел күңелемнән китми.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әтисе

ЗАКИРОВ Зөфәр Шамил улы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Татарстан Республикасы халыклары мәдәниятен һәм телләрен үстерү идарәсе мәдәният һәм сәнгатьне үстерү мәсьәләләре секторы мөдире Мифтахова Зәлия Зөфәр кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Уены-чыны бергә



Марат КӘБИРОВ

Мунча

1

Авыру әнисен карап, хастаханәдә озак кына ятканнан соң, авылына кайтып, беркадәр ял итеп килергә дип чыгып барган хатын капка төбендә үк бер авылдашын очрата. Яхшы танышы инде. Район үзәгендә яшиләр. Хәл-әхвәл белешкән арада хатын:

– Бүтәне бүтән, мунча керәсем килде, кайтуга шунда барам, – дип ычкындыра.

Ахирәте балкып китә:

– Бәй, безнең бит мунча ягылган, – дип елмая ул. – Әле автобус килгәнче әллә ничә тапкыр кереп чыга аласың.

Хатын шатланып риза була. Адресын сорый да шунда китә.

– Өйдә кеше юктыр әлегә, – дип кала ахирәте. – Туп-туры мунчага бар. Мин аңынчы әйләнеп кайтырмын.

Таксидан төшүгә хатын башы әйләнгәндәй тирәякка каранып тора. Берсеннән-берсе матур йортлар. Яши белә дә соң инде район үзәге халкы! Дөньялары әйләнеп чыккысыз.

Хатын ахирәте әйткәнчә туп-туры мунчага китә. Мунчалары да исең-акылың китмәле икән. Алгы якта кереп чишенә торган урыны, аннан юыну бүлмәсе, аннан парланып-чабынып чыга торган җир. Барысы да заманча матур итеп эшләнгән. Юынып чыгу гына түгел, яшәргә була монда.

Хастаханәдә ятып, юынуга сусаган хатын рәхәтләнеп мунча керә. Бер арада керләрен дә чайкап, пакетына сала. Аннан тагын кереп чабына. Шулай пыр тузып чабынып маташканда, мунчаның алгы ягында кемнеңдер кыштыр-мыштыр килгәнен ишетеп шым була…

2

Ир инде меңенче тапкыр бугай хатынына шалтырата. Тик тегесе, хәзер кайтып җитәм, ди дә һаман кайтмый. Тәмам тәкате корыгач, ир пыр тузынгандай итә. Хатыны тынычландыра: «Ярый, син барып юына тор, мин үз вакытым белән килермен». Ир ишеклетүрле йөренеп ала да, хатынының хаклы икәнен аңлап, мунчага үзе генә барырга була. Иректән файдаланып калырга кирәк. Суыткычтан ике шешә сыра ала, алмаш киемнәрен, сөлгесен тотып, мунчага китә.

Алгы бүлмәгә кергәч, бер бокал сыра җиппәрә. Чишенеп, кара киемнәрен кер машинасына ыргыта. Пиннекнең иң яхшы кебеген сайлап алып куя. Аннан соң тәненә бал сөртеп, аны сеңдерү өчен, тагын бер бокал сыра белән мунча алдында утыра. Эченә кергән сыра бераздан җыр булып чыга башлый, ир юк тавышы белән мөгрәп ала: «Их, кымызы, кымызы шул, бу кымызга ни җитә…» Кинәт мунча эчендә кыштырмыштыр килгән тавыш ишетеп, тынып кала. Тавыш та тына. Тамак кырып ала. Җавап ишетелми. Һәм ир, һоррор киноларындагыча, ишетелүгә тәнгә каз йоны чыгара торган сүзне кабатлый:

– Кем бар анда?

Җавап юк. Эчтә нәрсәдер шакылдап ала да озак вакытка тынып кала. Ир беркадәр шомланып тора да, үз ахмаклыгына елмаеп, сыра чөмереп куя. Кинәт ишек тарталар. Ул ачылып китә. Һәм…

3

Мунча алдына хатыны килеп керә дә ирнең иреккә чыгып, бәйрәм ясап утыруын күреп, кычкырып көлеп җибәрә:

– Кара әле, малай, үз кадереңне әйбәт беләсең син, ә! – ди ул ачусыз-нисез генә. – Сыраң бар, чипсы бар… Бәлки, берәр чәчбиең дә бардыр?

– Ә кәк же! – дигән була ир, хатынының кәефе барлыгыннан бәхетле булып, һәм юк тавышын бар итеп җырлап җибәрә:

Грузин чәе тәмле була
Эчсәң юкә бал белән…
Мунча керү рәхәт була
Сулдан килгән яр белән…

– Бирермен мин сиңа, менә, сулдан килгән ярны! – дип шаян шелтәли хатыны һәм назланып кына чишенергә тотына.

Ир этнекедәй тугры карашын аңа төбәп, сыра бокалын читкәрәк шудыра. Ипләп кенә якынлашып, аны кочаклап ала…

Нәкъ шул вакытта мунча ишеге ачылып китә. Ир белән хатын гөнаһ өстендә тотылгандай ишеккә карап катып калалар. Кинәт ачылган ишектән башта пар чыга, аннан соң яхшы итеп чабынып, бөтен тәне алсу төскә кергән зифа гәүдәле ялангач хатын. Хуҗабикә зәһәр карашларын иренә төби, ир иңнәрен җыера. Мунчадан чыккан хатын аптыраудан түгәрәкләнгән күзләрен ачып-йомып ала…

Соңыннан аңлашалар инде.

– Ахирәтең каршыдагы йортта тора бит ул, – дип көлә хуҗабикә. – Кая, үзен дә чакырыйм әле. Бергә көлсәң, күңеллерәк була ул.

ТӘРТӘ АРАСЫНА КЕРЕР ЧАК

ОЗЫН ЯЛЛАРДАН СОҢ НИЧЕК ГАДӘТИ ТОРМЫШКА КАЙТЫРГА?

Сәламәтлек

Чиксез тоелган ялларның да чигенә җиттек. Сер түгел, Яңа ел ялларында күпләр гадәти тормыштан читкә тайпылды. Дөрес туклану да, йокы режимы да онытылды. Элекке тормышка ничек кайтырга? Ничек уянырга һәм эш режимына күнегергә? Киңәшләребез шуңа бәйле булыр.

Йокыны куабыз!

Соң ятып, соң торылган көннәр артта калды. Эштә аягүрә йоклап йөрү уңайсызмы? Яллардан соң һәркемдә дә була торган хәл инде бу. Ничек уянырга соң? КФУның Университет клиникасы табибы, сомнолог **Лилия Шаһиәхмәтова** шуңа бәйле киңәшләре белән уртаклашты.

– Яңа ел яллары кешене элеккеге режимыннан чыгара. Моны булдырмый калу мөмкин түгел дә диярлек. Элекке режимга да кисәк кайтып булмый, – ди белгеч.

Соң булса да, уң булсын, эшкә чыгып өлгергәннәр өчен берничә киңәшебез бар.

– Яллар бетәргә дүрт көн кала 1–1,5 сәгать алдан, өч көн кала тагын да иртәрәк йокларга ятарга кирәк булыр. Шул рәвешле элеккеге йокы режимына кайтырга мөмкин, – ди табиб.

Лилия Шаһиәхмәтова белдергәнчә, яшь буын вәкилләре бозылган режимын тизрәк көйли. Күпчелек очракта йокыга бәйле проблемалар өлкән яшьтәге кешеләрдә барлыкка килә. Сүз уңаеннан, былтыр Университет клиникасы белгечләренә мондый проблема белән 100 кеше мөрәҗәгать иткән. Күпчелек – 71 кеше – ир-атлар.

Ашау-эчүне көйлибез!

Яшерен-батырын түгел: ялларда ризык тулы табын янында күп утырылды. Сыйландык та соң! Тик, бик туклыклы, әмма бик үк файдалы булмаган ризыклардан соң ашказанын стресстан коткарырга вакыт җитте. Көн дә бәйрәм өстәле булмас бит инде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Туклану режимын ничек җайга салырга?

- Көн дәвамында капкалап алулар турында онытырга туры килер. Ашаганда да, корсак тулганчы ашыйсы түгел: аз гына ач калсагыз да хәерле.
- Иртәнге ашка аеруча игътибар бирегез. Ашказанын майонезлы, итле, баллы, тозлы ризыклардан соң тәртипкә китерү өчен, аның туклыклы булуы гаять мөһим.
- Ризык порциясе Яңа ел ялларында ашаган порциядән 30–50 процентка кечерәк булырга тиеш.
- Аз-азлап 2–3 сәгать саен ашарга мөмкин.
- Ашый башларга 15 минут кала бер стакан җылы су эчәргә гадәтләнегез. Ашап-эчкәннән соң бер сәгать узгач, тагын бер стакан эчеп куярга мөмкин. Бу организмдагы шлакларны киметергә булышачак.
- Яңа ел табыныннан соң артык авырлык өстәлгәнен сизсәгез, һич кенә дә көннәр буе ач торырга ярамый! Бәйрәмнән соң шундук диетага утыру организмга кыенлык тудырачак.

Тән һәм рух саулыгын сакларга теләгәннәргә, Роспотребнадзор белгечләренең киңәшенә дә колак салу хәерле булыр.

Ялдан соң режимга кайткан мәлләрдә фаст-фуд, баллы ризыклар, исерткеч эчемлекләрдән баш тартып тору дөресрәк. Майлы, тозлы ризыклар да рационнан алынырга тиеш. Физик күнегүләр, саф һава турында да онытмагыз. Урамда, урманда, паркларда йөрү өчен ял биргәннәрен көтәргә кирәкми бит.

Психологик ярдәм

Рухи халәткә дә игътибар итәргә кирәк. Яңа елның тәүге эш атнасы җитди эшләргә алынмыйча, мөһим карарлар кабул итмичә узса яхшы. Эшкә акрынлап ияләшергә кирәк. Барысын да планлаштырып, баш миен ияләштереп, фикерне туплар өчен дә вакыт кирәк. Үзеңне шатландырып, «алда тагын яллар бар», «бу эш атнасы – кыска атна» дип, баш миен алдаласак та бик ярый.

Бу – кызык!

Ялллардан соң яңадан гадәти эш режимына ничек ияләшәсез? Эшкә тотынырга нәрсә этәргеч бирә? «Авито Работа» хезмәте халыктан шул хакта сораштырган.

14% – хезмәттәшләр белән очрашып сөйләшү
13% – дөрес туклану режимына күчү
12% – эшләрне планлаштыру, график төзү
11% – өй җыештыру
11% – иртәнге физик күнегүләр, спорт белән мавыгу
4% – яңа кирәк-яраклар сатып алу (көндәлек әйберләр, кием-салым)
4% – психикага бәйле күнегүләр ясау
4% – махсус видеолар карау

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Авыл фәлсәфәсе

«АБЗАРДА ТУГАННАР АБЗАРДА ЯШӘСЕН!»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яши-яши шуны аңладым: безнең гамәлләребезгә эте дә, бете дә бәя бирергә тырыша икән. Еш кына яхшы яктан түгел. Кешеләр генә димим. Туры мәгънәсендә, эте дә, мәчесе дә. Алар да, кешеләр кебек үк, синең яхшылыкларыңны минуты-секунды белән онытырга, сине кара исемлеккә куярга сәләтле. Яңа елның беренче салкыннары мине шуңа инандырды.

Декабрь башларында абзарда яшәүче мәчеләребезнең берсе бәбиләде (хәзер авылда өй саен дистәләп мәче, алар күбесенчә абзар-кура арасында яши. Бездә җиде ана мәче, аларны өйгә кертү мөмкин хәл түгел, өйдә әле бер шәһәр мәчесе бар). Бер ай буе алар әниләре саламны тирән итеп казып ясаган ояда яшәде. Декабрьдагы кырык градуслы суыкларда да туңмадылар. Әниләре яннарыннан да китмәде, ашарга гына бүленде. Яңа елга чыккач, алар инде үсте, ояда гына ятасылары килми башлады. Әниләре исә имезә дә иптәшләре янына китеп утыра. Кыш көне бәбиләгән мәче күргән юк иде – аларны нишләтергә дә белми аптырадык. Әле бозаулар ягына егылып төшәләр, әле каядыр кысылып калалар. Беркөн чыксам, туңганнар. Бөрешеп, калтырап утырганнарын күргәч, түзмәдем, өйгә алып кердем. Өйдә нәрсә буласын якынча күзаллый идем инде. Яз көне шулай, әнисе карамаган бер мәче баласын өйгә алып кергәч, шәһәр мәчесенең кыланмышын күреп, хәлдән тайган идек. Ул чакта көннәр җылытты да, бер атна качырып асрагач, мәче баласын урамга чыгарган идек. Ә монда дүртәү. Һәм алар теге мәче баласы кебек качып-посып ятарга гына риза түгел…

…Өйдәгеләр барысы да: «Бантик (өйдә генә яши торган шәһәр мәчесе – апамның балалары кайтаргандагы кушаматы калды) сине бигрәк ярата, синнән күзен дә алмый», – диләр иде. Дөрестән дә, ул мине аерым бер ярату белән ярата, мине аңлый кебек иде. Әз генә кәефем төшсә дә, кычкырыбрак сөйләшсәм дә, нәрсә булды дигәндәй эндәшеп, шул арада йөгереп килеп җитә. Мин дә аны вакыт булганда уйнатам, мунчада юындырам… Кыскасы, дуслыгыбыз ике яклы иде. Тик бу дуслык, мин дүрт мәче баласын өйгә алып керүгә, сабын куыгыдай шартлап юкка чыкты. Нәкъ кешеләр белән ике арадагы мөнәсәбәтләр кебек. Аз гына ялгышың булуга, кеше синең бөтен яхшылыгыңны оныта, гаепле-гаепсез дә дошманга әйләнүең тиз. Бантик белән дә шулай булды. Күзең белән күрмәсәң, ышана торган да түгел: үз телендәниләр генә кычкырмады ул кызым белән безгә (ул да мәче балаларының күзләрен дарулар белән чистартты, ашатты). Әйтү кыяфәтеннән «сатлыкҗаннар»ын да, «якын килмә», «ычкын моннан», «үзең аша, үзең эч»ләрен дә аңлап була иде.

Беренче көннәрдә бу хәлләр безгә әле кызык кебек тоелды. Кычкыра-кычкыра, сикереп килеп ябышуларын видеога төшереп алырга иде дип көлештек. Ә өченче көнне инде эш шаярудан узды. Бер тәүлек бер нәрсә ашамаган, эчмәгән Бантигыбыз авыруга сабышты. Юкса песи балаларын, аңа күрсәтмәс өчен, залга – авылча әйтсәк, түр өйгә бикләдек, ишеген дә ныклап ябып куйдык, тик бу гына ярдәм итмәде. Ике колагы ут кебек яна – температура! Бөгәрләнеп ята, килеп эндәшсәң, күзен тутырып карый да икенче якка борылып ята. Кызым белән икебезгә ул чын мәгънәсендә байкот игълан итте. Юкса мәче балалары берсеннән-берсе матур, йонлач, үзләре шулкадәр иркә. Йөгереп йөреп, шулар белән рәхәтләнеп уйныйсы гына бит инде.

Өйдәгеләр икегә бүленде: беребез Бантикны жәлләсә, икенчеләребез – дүрт мәче баласын.

– Чын эгоист ясагансбыз инде аннан, – ди бәләкәчләрне жәлләүчебез.

– Нәрсә, Бантик, сиңа дүрт бәби карарга кушалармы? – ди аның яклы булган әни. – Бәби тапканы юк бит аның, ул аларны каян ярата алсын…

– Эт тә гомере буе бәби тапмады, ата эт әле. Әмма бияләй кадәр мәче балалары да оясына кереп йөрде. Үзе тышта ятса ятты, ник берсенә сүз әйтсен. Бөтенесе аның янында иркәләнеп, аның азыгын ашап үстеләр, – дим.

Нәрсәдер эшләргә кирәк иде инде. Ике як та жәл. Уйлый торгач, ирем фанердан биек итеп, зур итеп тартма ясады. Бәләкәчләрне шунда салып, әлегә буш торган йокы бүлмәсенә күчердек. Рәхмәт төшкерләре, яраттылар әлеге тартманы! Асларына йомшак итеп йокы түшәге, бер почмакка кечкенә тартма белән туалет ясадык, азыкларын куярга да, уйнарга да урыннары калды.

Аларны күчереп, залны җыештыра башлауга, Бантик уртага кереп утырды. Кыяфәте! «Монда мин хуҗа!» – дип кычкырмый гына. Бераздан ялт кына чыгып ашап та керде, су да эчте. Аларны бөтенләй чыгарып җибәрделәр дип белдеме, тынычланды.

– Син җиңдең, Бантик, – минәйтәм. – Абзарда туганнар икән, абзарда яшәсеннәр, дигәнсеңдер инде…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 4668 данә
Гомуми тираж – 13856 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 202

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+